СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Мульма , ул.Центральная, 46А

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МҮЛМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк ур.46А

Тел./факс: +7(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**29 ноябрь 2018 ел** **№ 131**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56, 56 статьялары нигезендә Биектау муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәләренең беренче нөсхәләре нигезендә Җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзегән, 2018 елның 18 ноябрендә узган мәсьәлә буенча:

“2019 елда ел саен 18 яше тулган һәр кешегә 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме?”.

Үзара салым акчасы тотылучы төзекләндерү чаралары исемлеге:
- янгын гидранты сатып алу, урнаштыру; Мүлмә авылы эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- Сасмак авылы эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- Тимерче авылы коесын ремонтлау, материаллар сатып алу, киртәләү;
- Красна авылында күмелгән урыннарны карап тоту;
- Кызыл Болгар поселогында күмелгән урыннарны карап тоту;

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 822 референдумда катнашучы кертелгән;

Референдумда катнашучылар саны 530, бу 64,48 процент тәшкил итә;

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 286 кеше тавыш бирде, бу 53,96 процент тәшкил итә;

«Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 244 кеше тавыш бирде, бу 46,04 процент тәшкил итә.

**КАРАР БИРДЕ:**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдумны 2018 елның 18 ноябрендә узган дип танырга, ә референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга һәм референдум нәтиҗәләрен расларга.

"Сез 2019 елда Мүлмә авыл җирлеге территориясендә даими яшәү урыны буенча 18 яше тулган һәр кешегә 300 сум күләмендә ел саен бер тапкыр бирелә торган салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип санарга:

- янгын гидранты сатып алу, урнаштыру; Мүлмә авылы эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- Сасмак авылы эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- Тимерче авылы коесын ремонтлау, материаллар сатып алу, киртәләү;
- Красна авылында күмелгән урыннарны карап тоту;
- Кызыл Болгар поселогында күмелгән урыннарны карап тоту;

Әлеге карарны Мүлмә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча халыкка игълан итәргә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.А.Гарәфиев